| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ БОЛЬШЕНУРКЕЕВСКГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗУР НӨРКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 10 апреле № 114

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Советның 26.11.2021 ел, № 31 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 28.12.2024 елгы 540-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 49 пункты, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге Уставы нигезендә Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Советның 26.11.2021 ел, № 31 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.18 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) контроль (күзәтчелек) чарасы актын рәсмиләштергәннән соң контрольдә тотылучы затка мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең срокларын, шулай ук Контроль төре турындагы Федераль законда каралган башка чараларны күрсәтеп, күрсәтмә бирергә;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
Совет рәисе урынбасары Х.Ш.Шайхеразиев